**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең Арбаш авылында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2020 ел 26 ноябрь № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлегенең Арбаш авылыда халык җыены турында карар бирә:

1. 2021 елда Балтач районы Карадуган авыл җирлеге Арбаш авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзсалым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Х. Такташ урамында коймалар урнаштыру , баганалар сатып алу һәм аларны балалар уен мәйданчыгында (минифутбол) урнаштыру:
- Х.Такташ урамы буенча балалар уен мәйданчыгы (минифутбол) диварларын ныгыту өчен тимер-бетон плитәләр сатып алу һәм урнаштыру.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында ( pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе: Ш. В. Низамиев